Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының

« Яңа Бәзәкә» муниципаль берәмлегенең
Варклед-Аул торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре
турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**1 3 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 13ноябрендә 9 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Аул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ирләре яки хатыннары, балигъ булган балаларыннан), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (*лампалар, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, хезмәт килешүе буенча электрикка түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар*);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; чыгым материаллары, су белән тәэмин итү системасы өчен электротоварлар, су башнясын киртәләп алу өчен материаллар, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (*үләннәрне чабу; Варклед-Аул торак пункты янындагы җир кишәрлекләренең урман массивларына кушылган урыннарында янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны сөрү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм ягулык-майлау*

*материаллары сатып алу, янгын сүндерү машинасы өчен җылы гараж җиһазлау чыгымнары һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар*).

-торак пункт территориясен төзекләндерү *(Беларус-82.1 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт хакын хезмәт шартнамәсе буенча түләү); үләннәр чабу, авария хәлендәге һәм коры яшеллекләрне кисү, торак пункт урамнарын кардан чистарту, халыкның иминлегенә янаган агачларны кисү һәм башкалар;торак пункт территориясен төзекләндерү чыгымнары)*

башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 24 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 14 кеше, бу 58,33 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 14 катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Аул торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы « Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Аул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан), Iтөркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 800 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (*лампалар, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, хезмәт килешүе буенча электрикка түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар*);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; чыгым материаллары, су белән тәэмин итү системасы өчен электротоварлар, су башнясын киртәләп алу өчен материаллар, торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү

(*үләннәрне чабу; Варклед-Аул торак пункты янындагы җир кишәрлекләренең урман массивларына кушылган урыннарында янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны сөрү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу, янгын сүндерү машинасы өчен җылы гараж җиһазлау чыгымнары һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар*).

-торак пункт территориясен төзекләндерү *(Беларус-82.1 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу һәм штаттан тыш хезмәткәргә хезмәт хакын хезмәт шартнамәсе буенча түләү); үләннәр чабу, авария хәлендәге һәм коры яшелләкләрне кисү, торак пункт урамнарын кардан чистарту, халыкның иминлегенә янаган агачларны кисү һәм башкалар;торак пункт территориясен төзекләндерү чыгымнары)*.

4.Карарны Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы М.С.Салихов

